
ISSN 0868-4545

Салават күпере









Фәрит абыйның яшьләргә әйтер сүзе күп.

Бездә кунак бар

«Халкың өчен син бердәнбер булсаң,
Ул да сиңа газиз, бердәнбер!»

Кадерле дускай!

Бүген бездә кунак бар. Олы кунак. Син аны телевизор экраныннан еш күрәсең. Гәзит-журналларда басылган фотосурәтләре аша таныш ул сиңа. Хәер, журналыбызның ошбу битендәге фоторәсемгә күз салуга ук, сүзнең кем хакында барганлыгын чамалап алдың инде син, шулай бит?!

Әйе, Олы Кунак, дигәнебез – күренекле дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтче, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе **Фәрит Хәйрулла** улы **МӨХӘММӘТШИН.** Фәрит абыйның сөйләр сүзләре күп. Ул сөйләгән кайбер хатирәләр сине битараф калдырмас, дип уйлыйбыз.

– Сарман районының Иске Кәшер авылында туып үскән әти Бөек Ватан сугышына хәтле үк Әлмәткә укытучы булып килгән. Ул анда 1939 елга кадәр, ягъни, армиягә алынганчы тулай торакта яшәп, балалар укыткан. Хезмәт вакыты бетте генә дигәндә, сугыш башланган. Әти сугышның башыннан ахырына кадәр узып, 1945 елны исән–имин туган ягына кайткан.

© "Салават күпере", 2007 ел

Разил ВӘЛИЕВ

Бердәнбер

Бу дөньялар һәрчак болай булмас,
Тормышлар да әле көйләнер.
Берәү китә, берәү килә торыр,
Ватан калыр, Ватан — Бердәнбер.

Ватан белән бергә халык калыр,
Ил язмышы меңгә төрләнер...
Халык өчен син Бердәнбер булсаң,
Ул да сиңа газиз, Бердәнбер.

Еллар узар. Безнең бу көннәрне
Тарихчылар мең кат өйрәнер.
Тарих өчен – олы түрә булсаң,
Безнең өчен, син бит, Бердәнбер.



Фәрит абый әтисе Хәйрулла абый белән. 1998.

Әтиемнең гомере ятимлектә узган. Аңа бер яшь тулганда әтисе, ягъни минем бабай, үлеп китә. Әбием 1943 елда, әти сугышта чакта, вафат була. Әти, сугыштан кайткач, әнигә өйләнә һәм без 1947 елны гаиләбез белән Әлмәткә күчеп килгәнбез. Ул вакытта Әлмәт әле шәһәр түгел, гади бер авыл гына була.

Әти дөм ятим булса да, әнинең әти-әнисе, ягъни Мирзаян бабай белән Вәсилә әби, исән-саулар иде. Әлмәттә яшәгәндә еш кына аларга барып кунак булабыз. Ә инде әтине Әлмәттән Акташ районына күчергәч, безне, мәктәптә укыган балаларны, җәйге каникулларда Әлмәткә, шул әби-бабайларга җибәрәләр иде. Мин үземне-үзем белә башлаганнан бирле Акташ районында үстем. Дүртенче класска кадәр Рус Акташында укыдым.



Фәрит Хәйрулла улы МӨХӘММӘТШИНГА май аенда 60 яшь тулды. Хөрмәтле юбилярыбызны олуг бәйрәме белән ихлас котлыйбыз!



Фәрит абый – солдат.



Фәрит абый – шофер.

– Без Акташта яшәгәндә, авылга майор дәрәҗәсендәге бер гаскәри кайтты. Шундый чибәр кеше, матур итеп киенгән. Аягында хром итекләр. Без, сокланып, аның артыннан авыл буйлап ияреп йөрдек. «Менә мин армиягә китәрмен дә, укып, офицер булырмын», – дип, хыялланып йөрдем мин ул көннәрдә.

Әмма тормыш шартлары үзенекен итте. Тора-бара мин язмышымны нефтьчеләр белән бәйләдем. Әлмәт тулы нефтьчеләр бит, бөтен җирдә техника. Балачагыбыз шул скважиналарда, буровойларда, эшчеләр арасында үтте. Безне ачуланалар, куалар, ә без һаман шунда уйныйбыз, шунда тартылабыз. Әтинең: «Улым, нефтьче хезмәте авыр булса да, түләве яхшы. Татарстаныбызда нефть бездән соң да кала әле. Сиңа тырышып укырга кирәк. Нефтьче һөнәрен сайласаң, тормышың яхшы булыр», – дигән сүзләре әле дә колагымда.

***

– Луиза үзем өчен – акыллы, бик сөйкемле хатын, минем балаларымның әнисе, оныкларымның әбисе, дәү әнисе. Бу яктан без барыбыз да бик бәхетле. Кызым Лилия медицина университетын бетерде. Улым Дамир, финанс институтын тәмамлап, инде байтак еллар банк системасында эшли. Элек Милли банкта эшли иде, аннары, әти, миңа коммерция банкында эшләргә кирәк, өйрәнергә кирәк, дип, үзе теләп туган якка, Әлмәткә китте. Анда «Зенит»

банкының филиалында эшли. Кызым, институтны тәмамласа да, һаман укуын дәвам итә. Табиблар гомер буе укыйлар бит алар. Икесенең дә гаиләләре бар. Балалары үсә. Иншалла, балаларыбыз биткә кызыллык китермәделәр, киләчәктә дә, Алла боерса, китермәсләр. Ник дигәндә, гаилә безнең барыбыз өчен дә беренче урында тора. Бу гадәт әти-әнидән дә киләдер инде. Нинди гаиләдә нинди тәрбия аласың – шундый буласың, балаларың да, киләчәгең дә шундый була.

*(Шагыйрь Разил ВӘЛИЕВНЕҢ
Фәрит МӨХӘММӘТШИН
белән әңгәмәсеннән.)*



Фәрит абый оныгы белән.

Зиннур ХӨСНИЯР

Фәрит Мөхәммәтшинга

Хөр мәмләкәт -
монсы безнең язмыш,
Кичә булган, булыр иртәгә.
Убыр кануннары чатнап сынды
Юлларына куйган киртәңә.

Пәйгамбәрлек дәгъва итмәсәң дә,
Шуңа тарта исмең – Мөхәммәт.
Хәйруллалар ныклы нәсел иде,
Мөхәммәттән килгән шәп өммәт!

Көрәшәсе әле, яклыйсы бар,
Һәр канунда тормыш хаклыгы.
Чәчләреңдә еллар сафлыгы ул,
Кылган гамәлләрең аклыгы.

Дускай!
Кушбитләрдәге шигырьләрне игътибар белән укы. Төшенеп җитмәгән сүзләр очраса, аңлатуны сорап, өлкәннәргә мөрәҗәгать ит, яме!



Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА шигырьләре

Ә малай ат тугара...

Туплы уйный кыз бала,
(Ә малай ат тугара):
Тупны чөя, җиргә бәрә,
Тез астыннан чыгара.

Кайчак шулай булгалый:
Туп буйсынмый, тыңламый.
Тәгәри, китә читкә –
Бер урында торалмый.

Туплы уйный кыз бала,
Хисләрен өскә чөя...
...Ә малай ат тугара,
Малкаен сөя-сөя.

Табышмаклар

Мөгридер, «му»лыйдыр,
Койрыгын болгыйдыр,
Сөт, эремчек, май белән
Һәммәбезне сыйлыйдыр.
(Сыер.)

Өеңдә булыр байлык,
Төшеңдә күрсәң ...
(Балык.)

Урманында ул – патша,
Кыш көне кардан аста.
Уенда юктыр баю,
Бал яратадыр ...
(Аю.)

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Язилә

Җәй көне дә бездә яз,
Көз көне дә бездә яз,
Кыш көне дә бездә яз,
Бездә һәрчак көн аяз.
Сеңелемнең исеме
Бик матур шул: Язилә.
Язилә бер елмайса,
Өебезгә яз килә.
Хәтта елавы аның
Ләйсән яңгыр шикелле.
Нәни Язилә сеңлем
Язлар кебек сөйкемле.
Яз кызы өебездә,
Һәрчак яз шуңа бездә.

Дәрҗия

Безнең өйдә кунак бар –
Нәни генә тутый кош.
Зәңгәрсу күлмәк кигән,
Әйтерсең лә тәти кыз.
Исемнең дә без аңа
Куштык иң-иң матурын.
Хәзер өйдә Дәрҗиягә
Калмады бер ят урын.
Чишмә суы гына эчә,
Махсус җим генә ашый,
Баштүбән торып читлектә
Гимнастика да ясый.
Әтием аңа карый да
Мыек астыннан көлә:
– Юкка Дәрҗия түгел бу,
Үз дәрәҗәсен белә.



Алсу бакчага бара

Алсу бакчага йөри. Әмма иртә белән иртүк аның бакчага барасы килми. Алсу киреләнә, елый. Чөнки кичтән вакытында ятмаган иде ул. Шуңа күрә йокысы туймаган, ахры. Әллә башка сәбәпләре дә бармы? Шулай булса, Алсу тагын нинди сәбәпләр уйлап табар иде. Дускай! Әйдә Алсуга син дә ярдәм ит әле: бакчага бармас өчен, бергәләп сәбәпләр эзлик. Син аларны менә шушы юлларга яз. Әниең белән бергәләп, әлбәттә.

1. ______________________________
2. ______________________________
3. ______________________________



Дускай! *Сәбәпләрең ышандырырлык килеп чыкса, син аларны тиз генә «Салават күпере»нә җибәр. Берүк адресыңны язарга онытма! Иң матур хат авторына – бездән бик матур китаплар!*

«Салават күпере».

Адашкан алмалар

Дускай! Бу агачларга һәм аларның алма-җимешләренә игътибар ит әле! Тиздән җәй җитә. Агачлар чынлап торып җимеш бирә башлаячак. Рәссам хатасын төзәтергә ашык!



Рәссам Светлана ПРИВИНА





Рушан, 8 ай

– Әллү, җаным! Бер проблема
Килеп чыкты бит әле:
Бүген сиңа бара алмыйм –
Чәч үскәнен көтәмен!

Казан.



Луиза, 8 яшь
Рөстәм, 8 яшь

– Чиләкләрең мөлдерәмә –
Суы җиргә түгелә...
Чәчәк түгел, йөрәгемне
Бүләк итәм үзеңә!

Башкортостан, Авыргазы, Исмәгыйль.





Алинә, 5 яшь

– Ник уяндың? Йоклар идең,
Әле бик тә иртә, дим...
...Юри ачуланган булып,
Курчагымны иркәлим.

Актаныш, Такталачык.




Сөмбелә, 7 яшь

– Сайрар кошым, сандугачым
Талына кунса иде...
Тәүфыйклы, ипле егеткә
Насыйплар булсам иде!

Зәй, Югары Налим.

Шотландиядән хат…


BY AIR MAIL
par avion
Royal Mail
«Салават Күпере»
Мөхәрр
420012
Russia

«Салават Күпере»
Лервик
14.1.07

Хөрмәтле Мөхәррир,
Сәлам! Үзем белән таныштырырга рөхсәт итегез. Мин шотландияле телче, Шетландның утрауларында торам һәм татар телен өйрәнергә тырышам.
Балалар әдәбияты укырга бик файдалы. Шуңа күрә декабрь ахырына Казанда торгач, мин «Салават күпере» сатып алдым. Ул миңа бик ошады, аерым Кушыкта-Маюда бүреләр турында бик кызык. Аннан бал тагы: бүре надан түгел ә киресенчә «бик акыллы һәм зирәк җәнлек». Әмма ник шул ук журналның санында әкият (Җүләр бүре) бар һәм анда бүре акылсыз күренә? Бала ихтимал әкиятны истә тотар ә дәреслекне онытыр!
Уңышлар 2007нче елга телим сезгә!
Чын күңелдән
Derick Herring
(DERICK HERRING)
"Kazan"
Hayfield Court
Lerwick
Shetland
ZE1 0WN
Scotland U.K.

Хөрмәтле Мөхәррир!
Сәлам!

Үзем белән таныштырырга рөхсәт итегез. Мин шотландияле телче, Шетланд утрауларында торам һәм татар телен өйрәнергә тырышам.

Балалар әдәбияты укырга бик файдалы. Шуңа күрә, декабрь ахырында Казанда булгач, мин «Салават күпере» сатып алдым. Бүреләр турында бик кызык. Аннан бу тагы: бүре надан түгел, ә, киресенчә, «бик акыллы һәм зирәк җәнлек». Әмма ник шул ук журналның санында әкият («Җүләр бүре») бар һәм анда бүре акылсыз күренә? Бала, ихтимал, әкиятне истә тотар, ә дәреслекне онытыр!

2007 елга уңышлар телим Сезгә!
Чын күңелдән,
Дэрик ХЕРНИНГ.

Бөекбритания, Шотландия,
Шетланд утравы.

…Азнакайдан шигырь!

Шәп журнал

Бар журнал дөньяда,
Күпләргә терәк ул,
Бәйрәмнәр җиткәндә
Иң яхшы бүләк ул.

Һәрвакыт өйрәтә
Тик матур гадәткә:
Намуслы булырга,
Тәртипкә, әдәпкә.

Хәрефләр танымйм мин,
Саный да беләмен.
«Яса, – ди, – рәсемнәр», –
Тиктормас каләмем.

Иҗатка мәхәббәт
Кабынды җанымда.
Барсына ирештем,
Ул булгач янымда.

Шундый да яратып
Укыймын һәр санын.
«Салават күпере» –
Иң шәбе журналның.

Римма ШӘЕХОВА, 14 яшь.
Азнакай.




Земфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Тамчы сәяхәте



Тамчы иртүк уянды. Уянды да иркәләнеп киерелде. Як-ягына караса, әле берсе дә – Кояш та, үләннәр дә, Чишмә дә уянмаган. Шаян Тамчы: «Хәзер мин сезне уятам», – дип уйлады да, «тып» итеп, чирәмгә кунды. «Чык төште», – дип, күзен ачты Чирәм. Чирәмнең битен юды да, көлә-көлә чишмәгә сикерде Тамчы. «Уян, Чишмә, тизрәк уян, әйдә, куышлы уйныйбыз!» – диде ул, дустын ашыктырып. Йомры ташларның өстеннән сикерә-сикерә, яр читендәге чәчкәләргә су сибә-сибә, Чишмә белән Тамчы бик озак уйнадылар. Аларның тавышына Кояш та уянып чыкты. Чыкты да, йоклап кала язганын аңлап, тиз генә күкнең иң биек җиренә үрмәләде.

Чишмә белән Тамчы, шаярып уйный-уйный, инешкә барып җиттеләр. Инеш: «Ай-һай, күп эш!» – дип, зарланып, агып ята иде. Аның, чынлап та, эше күп шул: керләр чайкыйсы, үрдәк-каз бәбкәләрен йөзәргә өйрәтәсе, кечкенә бозауларга су эчерәсе... Тамчы белән Чишмә, көне буе Инешкә булышып, тәмам арып беттеләр.



Инеш тә арыды. «Әйдәгез, Елгага кунакка барып, ял итеп кайтыйк!» – диде ул Чишмә белән Тамчыга.

Аларның килүенә Елганың әллә ни исе китмәде. Анда болай да бик күп тамчылар, инешләр, чишмәләр бар иде инде. Тамчы үзенә бик күп дуслар тапты. Алар белән бергәләп, дулкын өстендә таган атынып уйнады.

«Их, Диңгезне дә күрәсе иде!» – диде Тамчы дусларына, уйнап туйгач. «Юл ерак шул», – диде Чишмә. «Ай-һай, барып җитеп булырмы икән?» – дип шикләнде Инеш. «Әйдәгез, миннән калмагыз. Миннән калмасагыз – адашмассыз!» – дип, Елга Тамчыны, Чишмәне һәм Инешне үз артыннан ияртте.

Бик күп көннәр, бик күп төннәр бардылар алар. Таулардан сикереп, дулкыннарга утырып, шарлавыкларда агып бара торгач, ак сакаллы Диңгезгә килеп тә җиттеләр. Як-якта ярлар да, агачлар да, үләннәр дә күренми. Ике якта да офык кына. Тамчы, диңгезне күргәч, куркып калды. «Мин монда югалырмын, адашырмын», – дип борчылды ул.

«Югалмассың, балам. Миңа бер тамчым да артык түгел. Мин сине дә саклармын», – диде аңа Диңгез.

Тамчы, әнә шулай итеп, бабасы Диңгез янында яшәп калды.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





Әкият дәвам итә...

Аю Әппәс белән Батыр

Шулай бик озак Аю Әппәстән куркып яшәгәннән соң, урман җәнлекләренең һәм кошларының түземлелеге беткән. Көннәрдән бер көнне, барысы бергә җыелышып, бик озак сөйләшкәннән соң, Аю Әппәсне урманнан куып җибәргәннәр. Аю Әппәс йөргән, йөргән дә бер урманны күргән. Урман янында бик матур бер авыл булган. Аю Әппәс авыл янындагы шул урманда яши башлаган. Үзе генә озак яшәгән Аю Әппәс. Аңа бик күңелсез була башлаган. Барып кайтыйм әле, кешеләрне дә күрермен, дип, авылга туп-туры киткән ул. Аю Әппәс килгәч, кешеләр куркуларыннан өйләренә кереп качканнар. Бер малай гына аннан курыкмаган. Аның исеме Батыр булган. Батыр, Аю Әппәс янына килеп, аңа кулын сузган. Әппәс куркып киткән. Әппәс әйткән Батырга: «Син миннән курыкмыйсыңмени?» – дигән. Батыр әйткән: «Юк», – дигән. Батыр Әппәстән: «Син нәрсә яратасың?» – дип сораган. «Бал», – дигән Әппәс. Батыр Әппәскә бал чыгарып биргән. Шуннан бирле Аю Әппәс һәм Батыр бик нык дуслашып киткәннәр. Алар бер-берсенә кунакка йөргәннәр. Кирәк вакытта ярдәмләшеп яшәгәннәр.

Аю Әппәс теге хәлләр турында бөтенләй онытқан ди.

Азат АХУНОВ, 11 яшь.
Яр Чаллы.



Халидә ИХСАНОВА, 9 яшь.
Яшел Үзән, Күгәй.



Оксана ВАСИЛЬЕВА, 10 яшь.
Кукмара, Кызылтау.

Куяннар куркак түгел

Бервакыт куяннар үз телләрен сагынып, Аю Әппәстән кача-поса сөйләшә башлаганнар. Боларның сөйләшкәнен хәйләкәр төлке ишетеп, Аю Әппәскә сөйләгән. Аю Әппәс барлык урман җәнлекләрен чакырган. Киңәшкәннәр, сөйләшкәннәр дә, куяннарга каршы чыкканнар. Куяннар шуннан бирле кача-поса яши башлаганнар. Алар әле дә Аю Әппәс телендә сөйләшмиләр ди.

Зилә ЗИННӘТУЛЛИНА, 10 яшь.
Арча, Мөндеш.

Горур кошлар

Аюның кошларга бик ачуы чыккан. Ул аларга: «Әгәр дә сез минем телемне өйрәнмәсәгез, мин сезнең бөтен ояларыгызны җимереп бетерәм!» – дигән. Кошлар аюның сүзенә карамаганнар, икенче зур урманга очып киткәннәр, шулай итеп үз телләрен саклап калганнар.

Җәнлекләр исә, ялагайланып, аю телен өйрәнергә керешкәннәр.

Ә кошлар әле дә үз телләрендә сайрашалар, серләшәләр, сөйләшәләр ди. Кешеләр аларны сокланып тыңлый.

Сиринә ГАЛИЕВА, 10 яшь.
Биектау, Чувашиле.



*Гадел БИЛДАНОВ, 10 яшь.
Нурлат, Корманай.*



*Алмаз ВӘЛИЕВ, 8 яшь.
Әгерҗе, Яңа Авыл.*



Безнең гаилә – кызык гаилә

Кадерле дускай!

Иң элек, әйдә, Тукай абыйның «Безнең гаилә» дигән шигырен искә төшерик әле:

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

Ә хәзер, әйдә, рәссам ясаган ошбу кызык сурәткә игътибар итеп алыйк. Мәзәк рәсем, шулай бит?! Йә, дускай, рәсемдәге әкәмәт ялгышларны җәһәт кенә әйтеп кара әле!

Бер уңайдан түбәндәге сорауларга да җавап әзерлә:

Сезнең гаиләдә ничә кеше яши? Исемнәрен дөрес итеп яз.

Өегездә песи яисә башка җан иясе бармы? Ул (алар) ни исемле?

Гаиләгездә булган кызыклы, күңелле хәлләрне исеңә төшер дә, шул хакта шигырь яки хикәя язып, рәсем ясап, журналханәгә хат юлла, яме! Иң кызыклы язмалар, рәсемнәр (фотосурәтләр дә ярый) журнал битләрендә урын алачак.

Йә, тотындыкмы эшкә?!






Рәссам Алла АЙСИНА



Рифкать абыйда кунакта



Дәүләт автомобиль инспекциясенең 70 еллыгына багышланган иң яхшы хикәягә, рефератка, тикшеренүгә конкурсны ЮХИДИ идарәсе белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы бергәләп үткәрделәр. Ул әүвәл мәктәпләрдә оештырылды. Аннары район, шәһәрләрнең җиңүчеләре билгеләнде. Аларның эшләре республика конкурсына тәкъдим ителде. Барлыгы 41 шәһәр һәм районнан 121 эш. Конкурста катнашучылар өч төркемгә бүленде. Беренче төркемгә 12 яшькә кадәрге балалар кертелгән иде. Түбән Камадагы 19 нчы мәктәп укучысы Гүзәлия Аликбәрова, Биектау районы, Озерная мәктәбеннән Айгөл Сафина, Әлки районы, Чуваш-Борнай мәктәбеннән «Иҗат» берләшмәсе, Балтач районы Кошкытбаш мәктәбеннән Ильяс Шаһиев беренче төркемдә җиңүчеләр булдылар.



Җиңүчеләрне Казанга чакырып кунак иттеләр. Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе хезмәткәрләре үзләренең музейларын күрсәттеләр, тәмле ашлар белән сыйладылар



һәм диплом, акчалата бүләк бирделәр. Бүләкләрне ЮХИДИ башлыгы Рифкать Миңнеханов үзе, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчеләре, шул исәптән министр урынбасары Айрат Зиннуров һәм башкалар тапшырды.

Япон кроссворды

17	6	6	6	7	7	8	8	9	9	8	7	4	2	1	1	1	1	3	3	3
1	1	1	1	3	2	2	4	6	6	3	1	1	1	1	6	7	9	7	2	2
	5	7	5	1	1	1	1	2	1	4	1	1	1	2	1	3	1	1	5	12
	4	1	1	2	1	2	2	1	1	1	1	1	1	1	1	4	4	3	1	1
	1	1	2	1	4	1	1				1	2	1	1	1	2	1	1	2	
			1	1	1	1	1				1	1	3	1	1	1	1	1	3	
			1	2	1	1					3	2	1	2	1				1	
				1							1	1	3	1	3					
											1	2	2	2	1					
												2	1	1	1					
												1	1	2						
														1						

Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА.

Кадерле малайлар, кызлар!

Өегезгә «Салават күпере» журналы килсә, балачакның күге гел кояшлы булыр, күңелегез төрледән-төрле төсләр яктысыннан балкып торыр.

Журналга язылу бәясе – ярты елга 84 сум.
Индексы – 73953.



5(206) — 2007

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТАТМЕДИА» МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯЛӘР АГЕНТЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: АГЕНТСТВО РТ ПО МАССОВОЙ КОММУНИКАЦИИ «ТАТМЕДИА», ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРУЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Иван ВОРОБЬЕВ рәсеме

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.
Казан, Декабристлар урамы,2 нче йорт.

Производствога бирелде 11.04.2007 ел.
Басарга кул куелды 11.04.2007 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 12285 данә. Заказ С-543.

Санны өзерләүчеләр:
З.Хеснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова, А. Вакказов.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Ләбиб ЛЕРОН

Акбай белән Кояш

Бакчадагы агачларга
Акбай карап шаккаткан:
Алмагач та, чияләр дә –
Һәммәсе дә ап-актан!

Аптыраган моңа Акбай –
Исе киткән, таң калган:
«Кичә генә кар юк иде,
Кай арада кар яуган?»

Акбайга карап торган да,
Кояш, елмаеп, әйткән:
– Кар яумаган, Акбай дустым,
Агачлар чәчәк аткан!